СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӨҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 86

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына, Шеңшеңәр авыл җирлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, «Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 85 номерлы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карары, «Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 12 номерлы Шеңшеңәр авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2019 елда Шеңшеңәр авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Шеңшеңәр авылында: зират коймасын төзекләндерү;

Комсомольская урамында урнашасы балалар өчен уен мәйданчыгы булдыру өчен җир кишәрлеге рәсмиләштерү, балалар уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, коймалап алу һәм төзекләндерү;

- Ор авылында: М. Җәлил урамындагы тыкрыкларның асфальт-бетон катламын ремонтлау, зиратта агач кисү, спорт мәйданчыгы төзү.

Эйе ЮК”

3. Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны “Хезмәт” район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Р.Х.Салихҗанов